Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советының утыз икенче утырышы

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

18 май, 2023 ел № 237

«Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районында өч һәм аннан күбрәк баласы булган гражданнарга Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының башка авыл җирлекләре чикләрендә җир кишәрлекләре бирү турында» 2019 елның 24 октябрендәге 221 номерлы Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Җир кодексының 32.1 статьясы нигезендә, өч һәм аннан да күбрәк баласы булган гражданнарга Питрәч муниципаль районы Богородский, Шигали, Кощаково авыл җирлекләре торак пунктларында буш җир кишәрлекләре булмауга бәйле рәвештә **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карар кабул итте:**

1. «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының өч һәм аннан күбрәк баласы булган гражданнарга җир кишәрлекләрен Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының башка авыл җирлекләре чикләрендә бирү турында» 2019 елның 24 октябрендәге 221 номерлы Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карарына (2021 елның 3 мартындагы 53 номерлы карары белән расланган үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- карарның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Богородский, Шигали һәм Кощаково авыл җирлекләре территориясендә даими яшәүче гражданнарга Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Күн һәм Шәле авыл җирлекләре территориясендә сайлау өчен җир кишәрлекләре бирелә»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Питрәч муниципаль районы Советының җирлекләрнең җирле үзидарә органнары белән үзара хезмәттәшлеге, законлылык, хокук тәртибе һәм регламенты буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Питрәч муниципаль районы башлыгы И.М. Кашапов